КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 декабрь г.Казань № 1252

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 24 сентябрь, 873 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 24 сентябрь, 873 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2018 – 2021 елларга» сүзләрен – «2018 – 2024 елларга» сүзләренә, «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибендә:

1.1 нче пунктта «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга;

1.2 нче пунктта:

алтынчы абзацта «эшмәкәрлек субъектларын урнаштыру өчен» сүзләре алдына «кече һәм урта» сүзләрен өстәргә;

тугызынчы абзацта «заявка бирүче» сүзләреннән соң «яки ышаныч кәгазе нигезендә ул вәкаләт биргән зат» сүзләрен өстәргә;

унөченче абзацта «А, С бүлекләре нигезендә төп эшчәнлекне гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары, экспортка» сүзләрен «А, С бүлек-

ләре нигезендә төп эшчәнлекне гамәлгә ашыручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары һәм (яки) экспортка» сүзләренә алыштырырга;

уналтынчы абзацта «әйләнештәге акчаны» сүзләреннән соң «(бу Тәртипнең 1.6 нчы пунктында күрсәтелгән чыгымнардан тыш)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«портал – «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://фасттрек.рф адресы буенча урнашкан, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен электрон төрдә ярдәм күрсәтү чараларыннан файдалану максатларында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының заявка һәм документлар бирүгә хокукларын тормышка ашыру өчен билгеләнгән белешмә-мәгълүмат ресурсы.»;

2.1 нче пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«заявка бирүче – юридик зат үзгәртеп оештыру, бетерү процессында тормый, аңа карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, аның эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән каралган тәртиптә туктатылмаган, ә заявка бирүче – индивидуаль эшмәкәр үз эшчәнлеген индивидуаль эшмәкәр буларак туктатмаган;»;

1.4 нче пунктта «2018 – 2021 елларга» сүзләрен – «2018 – 2024 елларга» сүзләренә, «2014 – 2021 елларга» сүзләрен «2014 – 2024 елларга» сүзләренә алыштырырга;

3.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«бу Тәртип кысаларында вәкаләтле затның заявка бирүгә һәм заявка составына керә торган документларга имза куюга хокукы булуын раслый торган, Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә (заявканы вәкаләтле зат биргән очракта).»;

3.6 нчы пунктның икенче абзацында «заявка бирү көненә карата» сүзләрен «килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәр килгән айның 10сына» сүзләренә алыштырырга;

4.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Сайлап алуда катнашу өчен заявка бирүче вәкаләтле оешмага заявканы кәгазь чыганакта яисә портал аша гариза бирүченең шәхси кабинетында махсус форманы тутыру юлы белән электрон рәвештә бирә.»;

4.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Заявка биргәндә тапшырыла торган барлык документлар, шул исәптән электрон төрдә бирелә торган документлар төгәл басылган һәм һәр пункты тутырылган булырга тиеш (мәгълүматлар булмаган очракта, сызык куела). Чистартып язулар һәм төзәтүләр рөхсәт ителми (мөһере (мөһере булганда) белән расланган һәм заявка бирүченең яки вәкаләтле затның имзасы белән таныкланган төзәтүләрдән тыш).

Кәгазь чыганакта бирелгән заявканың барлык битләре нумерланган булырга тиеш. Кәгазь чыганакта бирелгән заявка тегелгән булырга тиеш һәм заявканың икенче ягында, битләрнең гомуми санын күрсәтеп, заявка бирүче яки вәкаләтле затның имзасы һәм заявка бирүченең мөһере (мөһере булганда) белән расланган булырга тиеш. Электрон рәвештә бирелә торган документлар сканерлау чаралары ярдәмендә тулы төстә тапшыру режимында булдырылырга һәм гариза бирүче яки вәкаләтле зат тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә

идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасында авторизация юлы белән имзаланырга тиеш.»;

5.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Заявкалар кабул итүне вәкаләтле оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Заявкалар кабул итү чоры вәкаләтле орган карары белән билгеләнә һәм вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында заявкаларны кабул итә башлаган көнгә кадәр эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә басылып чыга.»;

6.1 нче пунктның икенче абзацында «нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» сүзләрен «нәтиҗәсе» сүзенә алыштырырга;

6.4 нче пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.4. Эш урыннары саны арту субсидия бирүнең нәтиҗәсе булып тора, аны исәпләп чыгару вәкаләтле оешма тарафыннан түбәндәге документлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

субсидия биргән айдан соң килә торган өченче ай хәленә карата Россия Федерациясе Пенсия фонды идарәсенең 2016 елның 1 февралендәге 83п номерлы карары белән расланган «Иминиятләштерелгән затлар турында мәгълүматлар» формасы буенча хисап күчермәсе (пенсия фонды органнарының хисаплылыкны кабул итү турындагы тамгасы белән яисә электрон цифрлы имза белән имзаланган электрон рәвештәге хисаплылыкны кабул итү һәм тикшерү турындагы документларны теркәп кертелә);

штат расписаниесе яки субсидия биргән айдан соң килә торган өченче ай хәленә карата эш урыннары саны турындагы мәгълүмат бирелгән башка документ.»;

бишенче абзацта «10 процентка» сүзләрен «5 процентка» сүзләренә алыштырырга;

6.5 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.5. Субсидия бирү турындагы килешү белән билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турындагы хисап субсидия алучы тарафыннан вәкаләтле оешмага бу Тәртипкә теркәлгән 5 нче кушымтада бирелгән форма буенча хисап чоры тәмамланган вакыттан алып 30 көн эчендә кәгазь чыганакта тапшырыла.»;

6.6 нчы пунктта «нәтиҗәлелек күрсәткечләре» сүзләрен «нәтиҗә» сүзләренә алыштырырга;

6.7 нче пунктның алтынчы абзацында «нәтиҗәлелеге күрсәткеченә» сүзләрен «нәтиҗәләренә» сүзләренә алыштырырга;

бу Тәртипкә теркәлгән 1 һәм 4 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә;

бу Тәртипкә теркәлгән 3 нче кушымтада «2018 – 2021 еллар» сүзләрен – «2018 – 2024 еллар» сүзләренә, «2014 – 2021 еллар» сүзләрен «2014 – 2024 еллар» сүзләренә алыштырырга;

бу Тәртипкә 5 нче кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибенә 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 30 декабрь, 1252 нче карары редакциясендә)

Форма

Субсидия бирүгә
гариза

| Т/с | Күрсәткеч исеме | Гариза бирүченең мәгълүматлары[1] |
|---|---|---|
| 1. | Гариза бирүченең тулы исеме | |
| 2. | ИНН | |
| 3. | КПП | |
| 4. | ОГРН | |
| 5. | ОКПО | |
| 6. | ОКТМО | |
| 7. | Юридик адресы | |
| 8. | Факттагы адресы | |
| 9. | Дәүләт теркәвенә алу датасы | |
| 10. | Банк реквизитлары, шул исәптән исәп-хисап счеты, корреспондент счеты, БИК | |
| 11. | Элемтәгә керү өчен телефон номеры | |
| 12. | E-mail | |
| 13. | Заявка биргән көнгә кредит шартнамәсе буенча фактта түләнгән процентлар суммасы | |
| 14. | Гариза бирүченең категориясе һәм нигезләмә (Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибе нигезендә) | |

[1] Барлык юллар тутырылган булырга тиеш. Мәгълүматлар булмаган очракта, сызык куела.

Бу заявкадагы һәм мин тапшырган теләсә нинди башка документлардагы минем шәхси мәгълүматларымны «Татарстан Республикасының Кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тарафыннан эшкәртүгә үземнең ризалыгымны белдерәм. «Татарстан Республикасының Кече һәм урта эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү һәм аны үстерү программаларын тормышка ашыру үзәге» дәүләт казна учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы шәхси мәгълүматларны системалаштырырга, тупларга, сакларга, аныкларга (яңартырга, үзгәртергә), кулланырга, таратырга (шул исәптән өченче затларга тапшырырга), тамгаларга, блокировкаларга һәм юк итәргә мөмкин.

Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибенең II бүлеге белән билгеләнгән таләпләргә туры килүемне, шулай ук гариза составында бирелгән документларның дөреслеген раслыйм.

Гариза бирүче

____________________/____________________________________________________________

(имзасы) (фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булганда)

М.У.

20__ел, «____»_________________

Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен субсидияләр бирү тәртибенә
4 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 30 декабрь, 1252 нче карары редакциясендә)

Форма

РИЗАЛЫК

____________________________________________________________ нигезендә эш итүче
(низамнамә, ОГРИП таныклыгы, ышанычнамә реквизитлары)
______________________________________________________________________________
(юридик затның исеме, индивидуаль эшмәкәрнең Ф.И.Ат.ис. (соңгысы - булганда))
_____________________________________________________________________ затында
(вазыйфасы, вәкаләтле затның Ф.Ис., Ат.ис. (соңгысы - булганда))
______________________________________________________________________________,
(оешма исеме)

бюджет ассигнованиеләре җитмәүгә бәйле рәвештә, субсидия күләме үзгәрү турында _____ елның _____________ ендәге(ындагы) _____ номерлы хәбәрнамә нигезендә бюджет ассигнованиеләре лимитларының калган өлеше күләмендә, ягъни ___________________ (_____________________________________________________ _______________________________________________________) сум _________ тиен
(суммасын таркатып язу)

субсидия бирүгә үземнең *(ризалыгымны/риза булмавымны)* ____________________
(дөресен язарга)

белдерәм.

__________________________ _________________________________________________
(имзасы) (Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы - булганда))

М.У.
20__ел, «____»_________________

__________________________________

Россия кредит оешмаларында җәлеп ителгән кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны каплау өчен субсидияләр бирү тәртибенә 5 нче кушымта

Форма

20__ елның _______________ хәленә карата
субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында
ХИСАП

Алучының исеме: _______________________________________________
Дәвамлылыгы: __________________________________________________

| Т/с | Нәтиҗә исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы буенча үлчәү берәмлеге | | Нәтиҗәнең план буенча мәгънәсе | Хисап көне хәленә карата нәтиҗәнең ирешелгән мәгънәсе | План үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | исеме | коды | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |

Хисапка түбәндәге раслый торган һәм тиешле рәвештә таныкланган документлар күчермәләре теркәлә:

1. Субсидия биргән айдан соң килә торган өченче ай хәленә карата Россия Федерациясе Пенсия фонды идарәсенең 2016 елның 1 февралендәге 83п номерлы карары белән расланган «Иминиятләштерелгән затлар турында мәгълүматлар» формасы буенча хисап (пенсия фонды органнарының хисаплылыкны кабул итү турындагы тамгасы белән яисә электрон цифрлы имза белән имзаланган электрон рәвештәге хисаплылыкны кабул итү һәм тикшерү турындагы документларны теркәп кертелә).

2. Штат расписаниесе яисә субсидия биргән айдан соң килә торган өченче ай хәленә карата эш урыннары саны турындагы мәгълүмат бирелгән башка документ.

Йомгаклау хисабын ______________________________________________
(Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда), вазыйфасы,
______________________________________________________________________
___ нче ышанычнамә, телефоны, e-mail)
______________________________________________________________________
тапшырды.

________________ ___________________
(имзасы) (имзаны таркатып язу)

Субсидия алучының элемтәгә керү өчен мәгълүматлар ___________________
(Ф.Ис.Ат.ис. (соңгысы – булганда),
______________________________________________________________________
вазыйфасы, телефоны, e-mail)

Субсидия алучы __________________ _____________ ____________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзаны таркатып язу)

М.У.

20__ел, «____»__________________

_________________________________